СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30. 01. 2025 г.Лениногорск № 3

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советының 2013 елның 19декабрендәге 98 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 12 декабрендәге 89-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советының 2013 елның 19 декабрендәге 98 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советының 30.07.2015 № 51, 30.03.2016 №51, 27.12.2016 № 114, 30.05.2017 № 38, 08.08.2017 № 63, 15.11.2017 №81, 19.01.2018 № 5,29.03.2018 № 18, 27.09.2018 № 56, 13.12.2018 № 80, 06.02.2019 № 4, 23.10.2019 № 56, 21.02.2020 №11, 12.11.2020 № 33, 26.03.2021 № 10, 06.08.2021 №45, 20.05.2022 № 28, 03.03.2023 № 8, 10.08.2023 №41, 17.10.2023 №52, 14.12.2023 №89, 24.04.2024 №31, 04.10.2024 №73, 27.11.2024 №89 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 2.6.1 пункт белән тулыландырырга:

«2.6.1. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының өлкән һәм (яисә) кече төркемнәре вазыйфаларын биләү өчен 2028 елның 1 гыйнварына кадәр һөнәри белем дәрәҗәсенә квалификация таләпләре куелмый (урта гомуми белем булганда), әгәр муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларга «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында" 2015 елның 25 апрелендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә катнашу керсә».».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы»муниципаль берәмлеге Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Лениногорск
муниципаль районы
Башлыгы урынбасары С.В.Тимаков